ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02 декабрь 2024ел № 8039

Башкарма комитетның 2022 елның 11 августындагы 4059 номерлы Карары белән расланган аукцион үткәрмичә, муниципаль милектәге җирләрдә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 11 августындагы 4059 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2022 елның 22 декабрендәге 7394 номерлы, 2024 елның 5 сентябрендәге 5726 номерлы Карарлары редакциясендә) расланган аукцион үткәрмичә, муниципаль милектәге җирләрдә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.5.1 пунктның 1, 3 пунктчаларын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1) шәхесне раслаучы документ (Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта таләп ителми);»;

«3) гариза:

кәгазь документ формасында (әлеге административ регламентка 4 нче кушымта);

Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, административ регламентның 2.5.3 пункты таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада (тиешле мәгълүматларны гаризаның электрон формасына кертү юлы белән тутырыла).»;

2) 2.5.2 пунктның 2 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2) Бердәм портал, Республика порталы аша электрон формада;»;

3) 2.5.3 пунктның беренче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.5.3. Гариза Бердәм портал, Республика порталы аша җибәрелгәндә, гариза бирүченең гади электрон имзасы белән имзалана.»;

4) 2.7.1 пунктның 5 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«5) гариза формасында, шул исәптән Бердәм порталда, Республика порталында гаризаның интерактив формасында мәҗбүри кырларны дөрес тутырмау (дөрес булмаганча, тулы булмаганча тутыру яки дөрес тутырмау);»;

5) 2.13.2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.13.2. Гаризаны Бердәм портал, Республика порталы аша җибәргәндә, гариза бирүче гариза биргән көнне Бердәм порталның, Республика порталының шәхси кабинетында һәм электрон почта аша, теркәү номеры һәм гариза бирү датасы күрсәтелә торган, гариза җибәрелүне раслаучы белдерү кәгазе ала.»;

6) 2.15.1 пунктка түбәндәге эчтәлектәге алтынчы абзац өстәргә:

«гариза һәм документлар Бердәм портал, Республика порталы аша электрон документлар формасында бирелгәндә, гариза бирүченең хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен Бердәм порталда, Республика порталында шәхси кабинет аша электрон рәвештә алу мөмкинлеге.»;

7) 2.16.1 пунктның 2, 6 пунктчаларын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2) Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешнең 7.2 пункты нигезендә электрон рәвешләре элек таныкланган документларны һәм мәгълүматны бирергә;»;

«6) Органның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) Бердәм портал, Республика порталы, муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан башкарылган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша шикаять бирергә.»;

8) 2.16.2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.16.2. Гаризаны формалаштыру, гаризаны нинди дә булса башка формада өстәмә рәвештә бирмичә, Бердәм порталда, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.»;

9) 3.2.3 пунктның беренче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.2.3. Гариза бирүче Органга телефон һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә, шулай ук Бердәм порталда, Республика порталында, Орган сайтында муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары, шул исәптән тапшырыла торган документлар составы, формасы һәм муниципаль хезмәттән файдалану өчен башка мәсьәләләр буенча консультация алырга хокуклы.»;

10) 3.3.2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.3.2. Бердәм портал, Республика порталы аша электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү өчен документлар кабул итү.»;

11) 3.7.1 пунктның бишенче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документта күрсәтелгән мәгълүматлардагы техник хатаны төзәтү турында гариза, гариза бирүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан почта аша (шул исәптән электрон почтадан файдаланып) яисә Бердәм портал, Республика порталы яки КФҮ аша бирелә.»;

12) аукцион үткәрмичә, муниципаль милектәге җирләрдә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымтаны кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 2 декабрендәге
8039 номерлы карарына
кушымта

Аукцион үткәрмичә, муниципаль милектәге җирләрдә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
4 нче кушымта

Форма

________________________________________
(җирле үзидарә органының исеме)

________________________________________

________________________________________
(оешманың һәм оештыру-хокукый формасының тулы исеме)

________________________________________

______________________________ исеменнән
(җитәкченең яки башка вәкаләтле затның Ф.И.А.и.)

Гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ:

________________________________________
(документ төре)

________________________________________
(серия, номер)

________________________________________
(кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

Юридик затны дәүләт теркәве турында мәгълүматлар:

ОГРН

________________________________________

________________________________________

ИНН

________________________________________

Урнашу урыны

________________________________________

________________________________________

Элемтә мәгълүматы:

тел. номеры ____________________

эл. почта ____________________

Стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга шартнамә төзү турында
ГАРИЗА

Стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга шартнамә төзүне сорыйм, сорала торган сәүдә урынының адрес ориентиры: ____________________________________,
объектның тибы ________________________________________________________________,
аннан файдалану максаты _________________________________________________________,
мәйданы _______ кв. м,
Стационар булмаган сәүдә объекты урынының номеры _______.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен түбәндәге ысул белән бирүне сорыйм:

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетына;

☐ Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетына;

☐ Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәгенә;

☐ Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетында.

______________                      _________________ ( ________________)
(дата)                                (имза)          (Ф.И.А.и.)

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы                      Н.И. Галиева